## «Минем эти – солдат» фотокүргәзмәсе

Озайтылган көн төркеме атналыгында «Минем эти - солдат» фотокүргәзмәсе оештырылды. Һәр гаиләдә яклаучылар бар: бабайлар, абыйларыбыз һәм, әлбәттә инде, безнең яраткан этиләребез. Ир-атлар хаклы рәвештә Ватаныбызны, туган ягыбызны саклаучылар булып санала. Балалар эти-әниләре белән өйдән этиләренең армиядә хезмәт иткән вакытта төшкән фотоларын алып килделәр, фотокүргәзмә ясадылар. Әлеге фотокүргәзмә балаларда Россия армиясе турында күзаллаулар формалаштыру, этиләрнең портретлары укучы балаларда үз армияләре өчен горурлык хисе, туганнарына мәхәббәт һәм этиләренә охшарга теләк тәрбияләү максатыннан эшләнде.

